# Тема:

# ***«Фатих Әмирхан хикәяләрендә кабатланган тема»***

***3 дәрес***

# әсәрләр:

*“Нәҗип”*

*“Корбан”*

*“Ул үксез бала шул! ” хикәяләре*

# Максат:

- **дидактик** - Ф.Әмирхан хикәяләрендәге кабатланган тема-кешенең үсүе, үзгәрүе темасының төрле яктан ачылуын аңларга ярдәм итү;
- **үстерелешле** -гомумиләштерү, охшаш күренешләр арасындагы бәйләнешне табу алымнарын формалаштыру;
- **тәрбияви**-төркемнәрдә ярдәмләшеп эшләү күнекмәләрен камилләштерү.

# Дәрес тибы:

***Уку мәсьәләсен чишү***

***Ориентлашу, мотивлаштыру этабы.***

1. Белемнәрне тигезләү:

а) Үткән дәреснең УМ нинди иде?

б) Ярым ижади һәм ижади өй эшләрен тыңлау.

2. УМ кую ситуациясе.

а)“Нәҗип”, “Корбан”, “Ул үксез бала шул! ” хикәяләреннән кечкенә-кечкенә өзекләр уку,

б)һәрберсенең сюжет һәм темасын кабат искә төшерү.

в)әсәрләр арасындагы охшашлык, бәйләнешне ачыклау.

## *II. Уку мәсьәләсен адымлап чишү этабы.*

**1нче бирем** ("Нәҗип")

Хикәяләрнең:

- сюжетын искә төшерү,
- темасын билгеләгеләү,
- метафораларны табу.

# Көтелгән җавап:

| Әсәр | Метафора | Тема |
| --- | --- | --- |
| “Нәҗип” | Уен:<br>1)урыннан кузгалмаган тарантас<br>2)йөзеп киткән көймә | Нәҗипнең үзгәрүе: мактанчык, ялган бер дөньяда яшәргә теләгән Нәҗип үзен җиңә. |

# 2нче бирем ("Ул үксез бала шул!")

## Көтелгән җавап:

| Әсәр | Метафора | Тема |
|---|---|---|
| "Ул үксез бала шул!" | Читек:<br>1)читек биек итеп күрсәтә<br>2)читек аркасында йөгерүдә артта кала | Нуриның иптәшләренең үзгәрүе: малайлар читек, бәйрәм күлмәкләре киеп, ятим Нурины мыскыллыйлар, ләкин хаталарын аңлыйлар, үкенәләр. |

# 3 нче бирем (“Корбан”)

Көтелгән җавап:

| Әсәр | Метафора | Тема |
| --- | --- | --- |
| “Корбан” | Корбан:<br>1)бәйрәм<br>2)корбан чалу, ягъни бәрәнне сую. | Малайның үзгәрмәве: ул үзенә бер дөнья уйлап таба һәм шул дөньяның корбаны була, чынбарлыкны аңларга теләми. |

## 4 нче бирем. 3 хикәяне таблицага карап гомумиләштерегез. Алар арасында охшашлыклар бармы?

<u>Көтелгән җавап</u>:

- һәрберсендә метафора бар,
- темалары охшаш – малайларның эчке кичерешләре.

# III.Рефлексия.

- Дәреснең УМ нинди иде?

Көтелгән җавап:

- “Нәҗип”, “Ул үксез бала шул!”, “Корбан” хикәяләре арасындагы охшашлык, бәйләнеш бармы- юкмы икәнлеген ачыкларга иде.

- Аны ничек чиштек?

Көтелгән җавап:

- Хикәяләрнең сюжетын искә төшердек, метафораларны таптык, темаларны билгеләдек, җавапларны таблицаларга тутырып, нәтиҗә ясадык.

# гомумиләштереп билге кую

а) терәк конспекттан, (тактадан, эш дәфтәрләреннән) файдаланып сөйләп бирә алса - «3»;

б) терәк конспекттан файдаланмыйча сөйли алса - «4»;

в) терәк конспекттан файдаланмыйча, сүзсез (в уме) үз-үзенә сөйли алса - «5».

# Өйгә эш

1. Ф.Әмирханның “Хәят” повестеның 1-7 бүлекләрен укырга, эчтәлеген сөйләргә(мәҗбүри).

2. Укылган өлештән төп каршылыкны табарга. Ул нидә? (Хәятнең күңелендә туган мәхәббәт хисе һәм аның бер хискә каршы көрәше турында язалар - яртылаш иҗади эш).

3. Хәятнең портретын рәсемгә төшереп карарга (иҗади эш).

- ***Танып-белү эшчәнлегенең методы:***
  - аңлатмалы-күрсәтмәле;
  - репродуктив;
  - өлешчә эзләнүле;
  - проблемалы ситуация тудыру;
  - өлешчә тикшерүле.
- ***Формасы*** – төркемнәрдә;
- ***Танып белү эшчәнлеге сыйфатын контрольдә тоту һәм бәяләү төре*** – үзконтроль, үзбәя ;
- ***Кулланылган чара*** – *дәреслек, такта, сүзлек, дәфтәр.*
- .

# Башкардылар:

1. Казнина Ясима Гайнетдиновна
(МБОУ «Ново-Ашапская ООШ»,
Барда муниципаль  районы, Пермь крае)

2. Кильдебаева Самига Самиковна
(МБОУ «Акбашевская ООШ»,
Барда муниципаль  районы, Пермь крае)